СОВЕТ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Ул. Чехова, д.18, с. Верхний Услон, 422570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ
Чехов ур., 18 нче йорт, Югары Ослан авылы, 422570

Тел.: (84379) 2-13-38, факс: (84379) 2-18-39. E-mail: sovet.uslon@tatar.ru, verhniy-uslon.tatarstan.ru

РЕШЕНИЕ | КАРАР

14.12.2020 с. Верхний Услон № 4-53

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районында муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007нче елның 2нче мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законга үзгәрешләр кертү белән бәйле,

Югары Ослан муниципаль районы Советы
карар итте:

1. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районында муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2. Нигезләмәнең 3.4нче бүлекнең 3.4.3нче пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.4.3. Җирле үзидарә органы, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппараты җитәкчесе булган муниципаль хезмәткәр, күрсәтелгән муниципаль хезмәткәрнең мәнфәгатьләр конфликтын төшереп калдыру максатларында әлеге җирле үзидарә органының сайланулы профсоюз органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында алар тиешле вазыйфаны биләгән чорда муниципаль хезмәткәрләр мәнфәгатьләрен тәкъдим итә алмыйлар»;

3. 4.1нче бүлегендәге 4.1.3нче пунктының 4нче пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. хезмәт кенәгәсен һәм (яки) хезмәт эшчәнлеге турында законнарда билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән белешмәләр, хезмәт килешүе (контракт) беренче тапкыр төзелгән очраклардан тыш»;

4. 8.1нче бүлек 8.1.1нче пунктының 4нче пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4) муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт кенәгәләрен алып бару (булганда), муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан муниципаль хезмәт узган чорда хезмәт эшчәнлеге турында мәгълүматлар формалаштыру һәм әлеге белешмәләрне мәҗбүри пенсия иминияте системасында индивидуаль (персональләштерелгән) исәпкә алу турында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә, Россия Федерациясе Пенсия фондының мәгълүмат ресурсларында саклау өчен бирү».

5. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Югары Ослан муниципаль районы Советының законлылык, хокук тәртибе һәм регламент буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Совет рәисе,
Югары Ослан муниципаль районы Башлыгы М.Г. Зиатдинов

Югары Ослан муниципаль районы
Советының 2020нче елның 14нче
декабрендәге 4-53нче номерлы
карарына

1нче кушымта

## 1. Гомуми Нигезләмәләр.

### 1.1. Муниципаль хезмәт.

Районның муниципаль хезмәте – хезмәт килешүе (контракт) төзү юлы белән башкарылучы муниципаль хезмәт вазифаларында даими нигездә тормышка ашырыла торган гражданнарның профессиональ эшчәнлеге.

Муниципаль хезмәткәрләр өчен яллаучы булып, аның исеменнән яллаучы вәкаләтләрен тормышка ашырган яллаучы (эш бирүче) муниципаль берәмлек тора.

Яллаучы (эш бирүче) вәкил булып Район Башлыгы, башка Район җирле үзидарә органы җитәкчесе яки яллаучы (эш бирүче) вәкиле вазифаларын башкаручы вәкаләтле шәхес була ала.

Югары Ослан муниципаль районында муниципаль хезмәт Россия Федерациясе Конституциясе, “Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында” Федераль законы, Татарстан Республикасының муниципаль хезмәт турында Кодексы, Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокук актлары, Югары Ослан муниципаль районы Уставы, бу Кагыйдәнамә, башка муниципаль хокук актлары белән туры китереп тормышка ашырыла.

Югары Ослан муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренә (алда- муниципаль хезмәткәр) “Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында” Федераль законында каралган үзенчәлекләр белән хезмәт кануны тәэсире таратыла.

### 1.2. Гражданнарның муниципаль хезмәткә керү юлына хокукы.

Россия Федерациясе дәүләт телен белгән гражданнар җенесенә, расасына, миллләтенә, теленә, килеп чыгышына, мөлкәт һәм хезмәттәге хәленә, яшәү урынына, дингә мөнәсәбәтенә, карашларына, иҗтимагый оешмаларга керүенә карамастан, шулай ук муниципаль хезмәткәрнең профессиональ һәм эшлекле сыйфатларына бәйле булмаган башка шартларга карамастан муниципаль хезмәткә тигез керүгә һәм тигез шартларга ия.

### 1.3. Районның муниципаль хезмәтен финанслау.

Районның муниципаль хезмәтен финанслау, федераль канун белән башка нәрсә каралмаган булса, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәтенә түләү чыгымнарын, аларны пенсия белән тәэмин итүне, муниципаль хезмәткәрләргә бирелә торган гарантияләрне тәэмин итү белән бәйле башка чыгымнарны кертеп, Районның җирле бюджеты хисабына тормышка ашырыла.

## 2. Муниципаль хезмәт вазифалары.

### 2.1. Муниципаль хезмәт вазифалары.

2.1.1. Районның муниципаль хезмәт вазифасы - Районның җирле үзидарә органындагы, Район Уставына туры китереп барлыкка килгән Районның башка муниципаль органнарындагы вазифа, вәкаләтләрне тормышка ашыру буенча билгеләнгән хезмәт вазифалары белән барлыкка килгән Районның башка муниципаль органнарында оешкан вазифа, яки муниципаль вазифа башкаручы.

2.1.2. Районның муниципаль хезмәте вазифалары Татарстан Республикасы муниципаль хезмәте вазифалары реестрына туры китереп Район муниципаль хокук актлары белән билгеләнә.

2.1.3. Районның җирле үзидарә органы, Районның Сайлау комиссиясе аппараты штаты расписаниесен төзегәндә һәм раслаганда Татарстан Республикасы муниципаль хезмәт вазифалары реестрында каралган муниципаль хезмәт вазифалары исемнәре кулланыла.

2.2. Муниципаль хезмәт вазифаларының классификациясе.

2.2.1. Районның муниципаль хезмәт вазифалары түбәндәге төркемнәргә бүленә:
1) югары муниципаль хезмәт вазифалары;
2) баш муниципаль хезмәт вазифалары;
3) әйдәп баручы муниципаль хезмәт вазифалары;
4) өлкән муниципаль хезмәт вазифалары;
5) кече муниципаль хезмәт вазифалары.

2.2.2. Татарстан Республикасы муниципаль хезмәт вазифалары һәм дәүләт граждан хезмәт вазифалары бәйләнеше, Татарстан Республикасы муниципаль хезмәт вазифалары һәм дәүләт граждан хезмәт вазифаларына тиешле квалификацион таләпләрне исәпкә алып, Татарстан Республикасы кануннары белән билгеләнә.

2.2.3. Муниципаль хезмәт вазифаларын алыштыру өчен квалификацион таләпләр Татарстан Республикасы кануны белән туры китереп билгеләнә.

2.2.4. 2020нче елның 1нче октябренә кадәр авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесенең (секретареның) урынбасары вазыйфасын биләү өчен һөнәри белем дәрәҗәсенә карата квалификация таләпләре урта һөнәри белем һәм муниципаль хезмәт стажына яисә белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча эш стажына кимендә ике ел яисә кимендә өч ел булуны күздә тота ала. 2020нче елның 1нче октябреннән соң муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы Кодексының 8нче статьясындагы 3нче өлешенең нче пунктында каралган күрсәтелгән вазыйфаны биләү өчен квалификация таләпләре 2020нче елның 1нче октябренә кадәр вазыйфага билгеләнгән муниципаль хезмәткәрләргә һәм әлеге пунктта каралган тиешле квалификация таләпләренә кулланылмый.

2.3. Район муниципаль хезмәткәрләренең класслы чиннары.

2.3.1. Класс чиннары муниципаль хезмәткәрләргә бирелә һәм муниципаль хезмәткәрләрнең һөнәри әзерлеге дәрәҗәсенең муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләү өчен квалификация таләпләренә туры килүен күрсәтә.

2.3.2. Районның муниципаль хезмәткәрләренә түбәндәге класслы чиннар бирелә:
Муниципаль хезмәтнең югары вазыйфаларын биләүче - 1, 2 яки 3 класслы гамәлдәге муниципаль киңәшче;
муниципаль хезмәтнең төп вазыйфаларын башкаручы - 1, 2 яки 3 класслы муниципаль киңәшче;
муниципаль хезмәтнең әйдәп баручы вазыйфаларын башкаручы - 1, 2 яки 3 класслы муниципаль хезмәт Киңәшчесе;
муниципаль хезмәтнең өлкән вазыйфаларын биләүче - 1, 2 яки 3 класслы муниципаль хезмәт референты;
муниципаль хезмәтнең кече вазыйфаларын биләп торучы - 1, 2 яки 3 класслы муниципаль хезмәт секретаре.

2.3.3. Югарыда күрсәтелгән төркемнәргә муниципаль хезмәт вазыйфаларын кертү Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт вазыйфалары реестры нигезендә гамәлгә ашырыла.

3. Муниципаль хезмәткәрнең хокук хәле

3.1. Районның муниципаль хезмәткәре.

3.1.1. Районның муниципаль хезмәткәре булып, федераль кануннар белән һәм Татарстан Республикасы кануннары белән туры китереп, Район муниципаль хокук актлары

билгеләгән тәртиптә Районның муниципаль хезмәт вазифалары буенча вазифа башкаручы, Район бюджетыннан түләнгән хезмәт хакы алып эшләүче гражданин тора.

3.1.2. Районның җирле үзидарә органнары һәм Районның башка муниципаль оешмалары эшчәнлеген техник тәэмин итү буенча вазифалар башкарган затлар Районның муниципаль хезмәте вазифаларын башкара алмый һәм муниципаль хезмәткәр булмый.

3.2. Районның муниципаль хезмәткәренең төп хокуклары.

3.2.1. Муниципаль хезмәткәр хокуклы:

1) муниципаль хезмәттә башкарган вазифалары буенча аның хокукларын һәм бурычларын билгеләүче документлар, хезмәт вазифаларын башкару сыйфатын билгеләүче критерийлар һәм хезмәт буенча күтәрү шартлары белән танышуга;

2) хезмәт вазифаларын башкару өчен кирәк булган оештыру-техник чараларны тәэмин итүгә;

3) хезмәт кануны, муниципаль хезмәт турында канун һәм хезмәт килешүе белән (контракт белән) туры китереп хезмәткә түләүгә һәм башка түләүләргә;

4) эш (хезмәт) вакытының тиешле дәвамлылыгын көйләү белән тәэмин итә торган ял, ял көннәре һәм бәйрәм көннәре, шулай ук еллык түләүле ялга;

5) билгеләнгән тәртиптә хезмәттәге вазифаларын башкару өчен кирәк булган материалларны һәм мәгълуматны алырга, шулай ук Районның җирле үзидарә органы, һәм Районның башка муниципаль органнары эшчәнлеген яхшырту турында тәкъдимнәрен кертүгә;

6) үз инициативасы буенча вакант муниципаль хезмәт вазифасына конкурста катнашырга;

7) муниципаль хокук акты белән туры китереп Район бюджеты хисабыннан өстәмә һөнәри белем алырга;

8) үзенең персональ мәгълуматларын сакларга;

9) үзенең шәхси делосының бөтен материаллары белән, һөнәри эшчәнлеге турында фикерләр һәм башка документлар белән аларны шәхси делосына керткәнче танышып чыгарга, шулай ук үзенең язмача аңлатмаларын шәхси делосына теркәргә;

10) профессиональ союзлар оештыру хокукын кертеп, иҗтимагый-икътисадый һәм профессиональ мәнфәгатьләрне, үзенең хокукларын яклау өчен оешырга;

11) хезмәт кануны белән туры китереп шәхси хезмәт бәхәсләрен карап тикшерергә, муниципаль хезмәттә үзенең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен якларга, аларны бозган очрак булса, судка шикаять бирергә;

12) Россия Федерациясе кануны белән туры китереп пенсия белән тәэмин итүгә.

3.2.2. Контракт буенча Башкарма комитет Җитәкчесе вазифасын башкаручы муниципаль хезмәткәрдән кала, муниципаль хезмәткәр, әгәр бу низах мәнфәгатьләре китереп чыгармаса һәм "Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында" Федераль законы белән башка нәрсә каралмаган булса, яллаучының (эш бирүченең) алдан бирелгән язмача белдерү кәгазе белән башка түләүле эшне башкарырга хокуклы

3.3. Муниципаль хезмәткәренең төп бурычлары.

3.3.1. Муниципаль хезмәткәр бурычлы:

1) Россия Федерациясе Конституциясе, федераль конституция законнары, федераль кануннар, Россия Федерациясенең башка норматив хокук актлары, Татарстан Республикасы Конституциясе, Татарстан Республикасының кануннары һәм башка норматив хокук актлары, Район Уставы һәм башка муниципаль хокук актларын үтәргә һәм аларның үтәлешен тәэмин итергә;

2) хезмәттәге күрсәтмәләр белән туры китереп хезмәттәге вазифаларын башкарырга;

3) хезмәт вазифаларын башкарган вакытта, расасы, милләте, теле, дингә карашы һәм башка хәлләргә карамастан, кешенең һәм гражданинның хокукларын, ирекләрен һәм законлы мәнфәгатьләрен сакларга, шулай ук организацияләрнең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен сакларга;

4) Районның җирле үзидарә органында һәм Районның башка муниципаль органнарында расланган эчке хезмәт кагыйдәләрен, хезмәттәге күрсәтмәләрне, хезмәт мәгълуматы белән эшләү тәртибен сакларга;

5) хезмәт вазифаларын тиешле башкару өчен кирәк булган квалификация дәрәҗәсен сакларга;

6) дәүләт һәм башка федераль кануннар белән саклана торган серне тәшкил иткән мәгълуматларны, шулай ук хезмәт вазифаларын башкару сәбәпле аңа билгеле булган мәгълуматларны, шул исәптән гражданнарның шәхси тормышына һәм сәламәтлегенә кагылышлы яки аларның намусына һәм абруена кагылган мәгълуматларны ачып салмаска;

7) дәүләт һәм муниципаль, шул исәптән аңа хезмәт вазифаларын башкару өчен бирелгән милекне сакларга;

8) Россия Федерациясе кануны белән билгеләнгән тәртиптә үзе һәм үзенең гаилә әгъзалары турында мәгълуматны тапшырырга;

9) яллаучыга (эш бирүчегә) Россия Федерациясе гражданлыгыннан чыккан көнне Россия Федерациясе гражданлыгыннан чыгу турында яки чит ил дәүләте гражданлыгын алган көнне чит ил дәүләте гражданлыгын алу турында хәбәр итергә;

10) “Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында” Федераль законы һәм башка федераль кануннар белән билгеләнгән чикләүләрне сакларга, йөкләмәләрен үтәргә, тыюларны бозмаска;

11) үзенең яллаучысына (эш бирүчесенә) язмача формада хезмәт вазифасын үтәгән вакытта низах мәнфәгатьләре китереп чыгарырга мөмкин булган шәхси кызыксынуы турында хәбәр итергә, һәм мондый бәхәсне булдырмый калу буенча чаралар күрергә.

3.3.2. Муниципаль хезмәткәр аңа бирелгән урынсыз йөкләмәне үтәргә хаклы түгел. Муниципаль хезмәткәр фикере буенча, тиешле җитәкчедән аңа бирелгән йөкләмә урынсыз икән, муниципаль хезмәткәр йөкләмәне биргән җитәкчесенә язмача формада, әлеге йөкләмәне үтәгән вакытта бозылырга мөмкин булган Россия Федерациясенең кануннары һәм башка норматив хокук актлары һәм Татарстан Республикасының кануннары һәм башка норматив хокук актлары кагыйдәнамәләрен күрсәтеп, әлеге йөкләмәнең урынсыз икәненә дәлилләр тапшырырга тиеш. Язмача формадагы әлеге йөкләмә тапшырган җитәкче тарафыннан расланса, муниципаль хезмәткәр аны үтәүдән баш тарта ала. Урынсыз йөкләмәне үтәгән очракта, муниципаль хезмәткәр һәм бу йөкләмәне тапшырган җитәкче закон белән туры китереп җаваплылыкка тартылалар.

3.3.3. Районның муниципаль хезмәткәре үзенең яллаучысына (эш бирүчесенә), прокуратура органнарына һәм башка дәүләт органнарына коррупцион хокук бозулар ясауга этәргән максат белән аңа ниндидер шәхесләрнең мөрәҗәгать иткән барлык очраклар турында хәбәр итергә тиеш.

Коррупцион хокук бозулар ясауга этәргән максаттагы мөрәҗәгать фактлары турында хәбәр, әлеге фактлар буенча тикшерү үткәрелүдән яки үткәрелгән очрактан кала, Районның муниципаль хезмәткәренең хезмәт (эш) вазифасы булып тора.

Муниципаль хезмәткәренең хезмәт (эш) вазифасын үтәмәүе Россия Федерациясе кануны белән туры китереп аны муниципаль хезмәттән азат итү яки башка җаваплылыкка тартуга китергән хокук бозу була.

Үзенең яллаучысына (эш бирүчесенә), прокуратура органнарына һәм башка дәүләт органнарына коррупцион хокук бозулар ясауга этәргән максат белән аңа ниндидер шәхесләрнең мөрәҗәгать иткән барлык очраклар турында, башка муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан коррупцион хокук бозулар турында, керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәт характерындагы бурычлары турында мәгълуматларны тапшырмаган яки дөрес һәм тулы булмаган мәгълуматларны тапшыру турында хәбәр иткән районның муниципаль хезмәткәре Россия Федерациясе законы белән туры китереп дәүләт яклауында була.

Районның муниципаль хезмәткәрен коррупцион хокук бозулар ясауга этәргән максат белән аңа ниндидер шәхесләрнең мөрәҗәгать иткән барлык очраклар турында хәбәрне яллаучыга (эш бирүчегә) тапшыру тәртибе, хәбәрләрдә булган барлык мәгълуматлар, бу мәгълуматларны тикшерүне оештыру һәм хәбәрләрне рәсмиләштерү тәртибе яллаучы (эш бирүче) тарафыннан билгеләнә.

3.4. Районның муниципаль хезмәте белән бәйле чикләүләр

3.4.1. Гражданин Районның муниципаль хезмәтенә алына алмый, ә Районның муниципаль хезмәткәре Районның муниципаль хезмәтендә түбәндәге очракларда була алмый:

1) законлы көченә кергән суд карары белән аны хезмәткә яраксыз яки чикле хезмәткә яраклы дип тапканда;

2) муниципаль хезмәт вазифасы буенча хезмәттәге вазифаларын башкару мөмкинлеген юкка чыгарган законлы көченә кергән суд карары буенча ул җәзага тартылса;

3) муниципаль хезмәт вазифасы буенча хезмәттәге вазифаларын башкаруга дәгъва кылган гражданин, мондый мәгълуматлар куллану белән бәйле булып, дәүләт һәм башка федераль кануннар белән саклана торган серне тәшкил иткән мәгълуматларга керүгә хокукны рәсмиләштерү процедурасын үтүдән баш тартса;

4) Районның муниципаль хезмәтенә керү өчен комачаулаган яки аны үтүгә һәм медицина оешмасы тарафыннан нәтиҗә белән расланган авыруы булса. Диспансеризация узу тәртибе, мондый авыруларның исемлеге һәм медицина оешмасы тарафыннан ясалган нәтиҗә формасы Россия Федерациясе Хөкүмәтеннән вәкил булган башкарма хакимиятнең федераль органы тарафыннан билгеләнә;

5) муниципаль хезмәт вазифасын башкару бу хезмәттәге шәхескә турыдан-туры буйсыну яки контрольле булу белән бәйле булса, районның башкарма комитеты җитәкчесе белән якын туган яки туганлык мөнәсәбәтләре (әти-әнисе, ирле-хатынлы, балалары, абый-апалары, эне-сеңелләре, шулай ук ир- хатынның балалары, абый-апалары, эне-сеңелләре һәм балаларының ир-хатыннары) булса, яки муниципаль хезмәт вазифасын башкару турыдан-туры берсенең икенчесенә буйсыну яки контрольле булуы белән бәйле булган муниципаль хезмәткәр белән якын туган яки туганлык мөнәсәбәтләре булса;

6) Россия Федерациясе гражданлыгы бетсә, Россия Федерациясе халыкара килешү катнашучысы-чит дәүләт гражданлыгы бетә, чит дәүләт гражданлыгын яки торырга рөхсәт алса, шуңа күрә чит ил гражданины Районның муниципаль хезмәтендә булса;

7) Районның муниципаль хезмәткәре Россия Федерациясе халыкара килешү катнашучысы-чит дәүләт гражданины белән туры китереп чит ил гражданины Районның муниципаль хезмәтендә булырга хокуклы булган очрактан тыш чит дәүләт (чит дәүләтләр) гражданлыгы булса;

8) Районның муниципаль хезмәтенә кергәндә ялган документлар һәм мәгълуматлар тапшырса;

9) муниципаль хезмәтенә кергәндә “Коррупциягә каршы тору турында” 2008нче елның 5нче декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законы һәм башка федераль кануннарда билгеләнгән мәгълуматлар тапшырмаса яки дөрес булмаган һәм тулы булмаган мәгълуматларны тапшырса;

9.1) “Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында” Федераль законының 15.1нче статьясы белән күздә тотылган мәгълуматлар тапшырмаса;

10) Татарстан Республикасы хәрби хезмәткә алу комиссиясенә күрсәтелгән нәтиҗәгә шикаять бирү өчен билгеләнгән вакыт узганнан соң 10 ел эчендә хәрби хезмәткә алу комиссиясе нәтиҗәсе белән туры китереп, моңа законлы нигез булмыйча, аны хәрби хезмәткә алу буенча хәрби хезмәтне узмаган дип танысалар (контракт буенча хәрби хезмәтне узган гражданнардан кала), әгәр гражданинның шикаяте буенча күрсәтелгән нәтиҗә һәм (яки) Татарстан Республикасы хәрби хезмәткә алу комиссиясе карарына судка шикаять бирелгән булса, суд карары көченә кергән көннән 10 ел эчендә бу карарны чыгарган вакытта гражданинның хокуклары бозылмаган дип табыла.

3.4.2. Гражданин Районның муниципаль хезмәтенә Район муниципаль хезмәтен башкару өчен билгеләнгән соңгы яшь - аңа 65 яшь тулганнан соң алына алмый.

3.4.3. Җирле үзидарә органы, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппараты җитәкчесе булган муниципаль хезмәткәр, күрсәтелгән муниципаль хезмәткәрнең мәнфәгатьләр конфликтын төшереп калдыру максатларында әлеге җирле үзидарә органының сайланулы профсоюз органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе

аппаратында алар тиешле вазыйфаны биләгән чорда муниципаль хезмәткәрләр мәнфәгатьләрен тәкъдим итә алмыйлар.

3.5. Районның муниципаль хезмәте белән бәйле тыюлар

3.5.1. Муниципаль хезмәт башкару сәбәпле Районның муниципаль хезмәткәренә тыела:

1) көчен югалткан;

2) түбәндәге очракларда муниципаль хезмәт вазифасын алыштырырга:

а) Россия Федерациясе дәүләт вазифасына яки Татарстан Республикасы дәүләт вазифасына сайлану яки билгеләнү, шулай ук дәүләт хезмәте вазифасына билгеләнгән очракта;

б) муниципаль вазифага сайлану яки билгеләнү;

в) профессиональ союз органында сайлап куелган түләүле вазифага, шул исәптән Районның җирле үзидарә органында оешкан сайлап куелган беренчел профсоюз оешмасына сайлану;

3) шәхси яки ышанычлы затлар аша эшмәкәрлек эшчәнлеге белән шөгыльләнергә, коммерция оешмасы белән идарә итүдә яки коммерцияле булмаган оешма белән идарә итүдә катнашырга (сәяси партия белән идарә итүдә катнашудан тыш); һөнәри берлек органы, шул исәптән районның җирле үзидарә органында төзелгән беренчел профсоюз оешмасының сайлау органы белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашу; съездда (конференциядә) яки башка иҗтимагый оешма, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативлары, бакчачылык, яшелчәчелек, дача кулланучылар кооперативлары, күчемсез милекчеләр ширкәтләренең гомуми җыелышында катнашу; күрсәтелгән коммерциячел булмаган оешмалар белән идарә итүдә (сәяси партиядән һәм һөнәри берлек органыннан, шул исәптән районның җирле үзидарә органында төзелгән беренчел профсоюз оешмасының сайлау органыннан тыш) түләүсез нигездә катнашуның яисә аларның коллегиаль идарә итү органнары составына эшкә алучы (эш бирүче) вәкиле рөхсәте белән кергән, муниципаль хокукый акт белән билгеләнгән тәртиптә алынган), муниципаль район идарә һәм ревизия комиссиясе органнарында, гамәлгә куючы (акционер) район мәнфәгатьләрен түләүсез нигездә тәкъдим итүдән тыш, муниципаль берәмлек исеменнән муниципаль милектә булган оешмалар яки идарә итүне гамәлгә куючы вәкаләтләрен гамәлгә ашыру тәртибен билгели торган муниципаль хокукый актлар нигезендә (устав капиталында катнашу өлешләре) муниципаль район милке булган акцияләр белән идарә итүне тормышка ашыру; федераль законнарда каралган башка очракларда;

4) федераль кануннар белән башка нәрсә каралмаган булса, Районның җирле үзидарә органында өченче зат эшләре буенча ышанычлы вәкил булырга;

5) хезмәттәге урыны яки хезмәттәге вазифаларын башкару сәбәпле физик һәм юридик затлардан бүләкләр (бүләкләр, акчалата бүләкләр, ссудалар, булышлык, күңел ачулар, яллары, трансполрт чыгымнары өчен түләүләр һәм башка бүләкләр) алырга. Беркетмәле чаралар, хезмәт командировкалары белән һәм башка рәсми чаралар үткәрү сәбәпле алынган бүләкләр, Россия Федерациясе Гражданнар кодексы билгеләгән очраклардан кала, муниципаль район милке булып санала һәм тиешле муниципаль оешмага акт буенча тапшырыла. Район Башлыгы вазифасын, даими нигездә муниципаль вазифаны башкарган зат аның беркетмәле чаралар, хезмәт командировкалары белән һәм башка рәсми чаралар үткәрү сәбәпле алган тапшырган бүләкләрне Россия Федерациясе норматив хокук актлары белән билгеләнгән тәртиптә сатып ала ала;

6) Районның җирле үзидарә органнарының башка муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнары белән, шулай ук чит дәүләтләрнең дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары белән, коммерцияле булмаган чит ил оешмалары белән үзара килешү буенча тормышка ашырылган командировкалардан кала, физик һәм юридик затларның акчалары хисабына командировкаларга барырга;

7) хезмәт вазифаларын башкару белән бәйле булмаган максатларда материаль–техник, финанс һәм башка тәэмин итү чараларын, башка муниципаль милекне файдаланырга;

8) федераль кануннарга туры китереп, конфиденциаль характердагы мәгълуматларга караган мәгълуматларны, муниципаль хезмәт вазифаларын башкарган вакытта

муниципаль хезмәт эшчәнлеге белән бәйле булмаган үзенә билгеле булган мәгълуматны таратырга һәм шул максатларда кулланырга;

9) бу аның хезмәттәге вазифаларына кермәсә, Районның җирле үзидарә органнары һәм аларның җитәкчеләренең эшчәнлегенә кагылышлы мәгълуматны халык алдында әйтергә, тикшерергә һәм бәя бирергә, шул исәптән массакүләм мәгълумат чараларында бастырып чыгарырга;

10) Район Башлыгының язмача рөхсәтеннән башка, күрсәтелгән оешмалар белән үзара бәйләнеш аның хезмәттәге вазифаларына керсә, чит ил дәүләтләре, халыкара оешмалар, шулай ук сәяси партияләр, башка иҗтимагый оешмалар һәм дини оешмаларның бүләкләрен, мактаулы һәм махсус (фәнни исемнән кала) исемнәрен кабул итергә;

11) хезмәттәге хәле өстенлекләрен сайлау алды агитациясе өчен, шулай ук референдум мәсьәләләре буенча агитация өчен кулланырга;

12) үзенең хезмәттәге хәлен сәяси партияләр, башка иҗтимагый оешмалар һәм дини оешмаларның мәнфәгатьләрендә кулланырга, шулай ук муниципаль хезмәткәр сыйфатында бу оешмаларга карата мөнәсәбәтен халык алдында белдерергә;

13) Районның җирле үзидарә органнарында, башка муниципаль органнарда сәяси партияләр, башка иҗтимагый оешмалар (профессиональ союзлар, шулай ук ветеран һәм башка иҗтимагый үзешчән органнардан кала) һәм дини оешмаларның структураларын оештырырга яки күрсәтелгән структураларның оешуына булышырга;

14) хезмәткә карата дәгъваны җайлау өчен хезмәт вазифаларын башкаруны туктатырга;

15) Россия Федерациясе халыкара килешүе һәм Россия Федерациясе кануны белән башка нәрсә каралмаган булса, идарә итү органнары, попечительләр һәм күзәтчелек советлары, башка чит ил коммерцияле булмаган хөкүмәтнеке булмаган оешмалар составына һәм Россия Федерациясе территориясендә эшләп килүче аларның структур бүлекчәләре составына керергә;

16) Россия Федерациясе халыкара килешүе һәм Россия Федерациясе кануны белән башка нәрсә каралмаган булса, яллаучы (эш бирүче) вәкилнең язмача рөхсәтеннән башка чит ил дәүләтләре, халыкара һәм чит ил оешмалары, чит ил гражданнары һәм гражданлыгы булмаган шәхесләр акчасы хисабына финанслана торган түләүле эшчәнлек белән шөгыльләнергә.

3.5.2. Контракт буенча Башкарма комитет җитәкчесе вазифасын башкаручы Районның муниципаль хезмәткәре укыту, фәнни һәм башка иҗади эш белән шөгыльләүдән кала, башка түләүле эшчәнлек белән шөгыльләнергә хокуклы түгел. Өстәвенә укытучылык, фәнни һәм башка иҗади эш өчен түләү, Россия Федерациясе кануннарында һәм Россия Федерациясе халыкара килешүе белән башкача каралмаган очракта, чит дәүләт хисабына, халыкара һәм чит ил оешмалары, чит ил гражданнары акчасы хисабына була алмый. Контракт буенча Башкарма комитет Җитәкчесе вазифасын башкаручы Районның муниципаль хезмәткәре Россия Федерациясе халыкара килешүе һәм Россия Федерациясе кануны белән башка нәрсә каралмаган булса, идарә итү органнары, попечительләр һәм күзәтчелек советлары, башка чит ил коммерцияле булмаган хөкүмәтнеке булмаган оешмалар составына һәм Россия Федерациясе территориясендә эшләп килүче аларның структур бүлекчәләре составына керергә хокуклы түгел.

3.5.3. Районның муниципаль хезмәтеннән чыкканнан соң гражданинның конфиденциаль характердагы мәгълуматларны яки муниципаль хезмәт вазифаларын башкарган вакытта үзенә билгеле булган мәгълуматны таратырга һәм оешма мәнфәгатьләрендә кулланырга хакы юк;

3.5.4. Норматив хокук актлары белән билгеләнгән вазифалар исемлегенә кергән муниципаль хезмәт вазифасын башкарган гражданин муниципаль хезмәтеннән чыкканнан соң ике ел эчендә, әгәр гамәлдәге канун белән билгеләнгән тәртиптә муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибенә таләпләрне саклау һәм ихтыяҗ бәхәсләрен җайга салу буенча комиссиянең тиешле ризалыгыннан башка әлеге оешманың аерым муниципаль (административ) функцияләре муниципаль хезмәткәрнең хезмәт (эш) вазифаларына кермәгән булса, хезмәт килешүе шартлары нигезендә оешмада вазифа башкарырга һәм (яки) бу оешмада федераль канун белән каралган очракта граждан–хокук килешүе шартларында эш башкарырга хаклы түгел.

### 3.6. Районның муниципаль хезмәткәренең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәт характерындагы йөкләмәләре турында мәгълуматлар

3.6.1. Югары Ослан муниципаль район Советы Карары белән расланган исемлеккә кергән муниципаль хезмәт вазифасын башкаруга дәгъва кылучы гражданин, шулай ук Югары Ослан муниципаль район Советы Карары белән расланган исемлеккә кергән муниципаль хезмәт вазифасын башкаручы хезмәткәр, ел саен яллаучы (эш бирүче) вәкилгә үзенең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәт характерындагы йөкләмәләре турында мәгълуматларны һәм хатыны (ире) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәт характерындагы йөкләмәләре турында мәгълуматларны тапшырырга тиеш. Күрсәтелгән мәгълуматлар Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәт характерындагы йөкләмәләрне тапшыру өчен билгеләнгән тәртиптә, вакытта һәм формада тапшырыла.

Югары Ослан муниципаль район Советы Карары белән расланган исемлеккә кергән муниципаль хезмәт вазифасын башкаручы муниципаль хезмәткәр ел саен үзенең чыгымнары турында мәгълуматларны һәм хатыны (ире) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары турында мәгълуматларны Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәт характерындагы йөкләмәләрне тапшыру өчен билгеләнгән тәртиптә, вакытта һәм формада тапшырырга тиеш.

Муниципаль хезмәткәрнең, аның хатыны (ире) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары керемнәре белән туры килүне контрольдә тоту “Коррупциягә каршы тору турында” 2008нче елның 25нче декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законы һәм “Дәүләт вазифасын башкаручы затларның һәм башка затларның кереме белән чыгымнары туры килүен тикшерү турында” 2012нче елның 3нче декабрендәге 230- ФЗ номерлы Федераль законы, Россия Федерациясе Президентының норматив хокук актлары, Татарстан Республикасы кануннары һәм норматив хокук актлары, муниципаль хокук актлары белән каралган тәртиптә тормышка ашырыла.

3.6.2. Муниципаль хезмәткәр тарафыннан тапшырылган керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәт характерындагы йөкләмәләре турында мәгълуматлар, федераль канун белән алар дәүләт серен тәшкил итүче мәгълуматларга карамаса, конфиденциаль характердагы мәгълуматлар була.

3.6.3. Муниципаль хезмәткәрнең, аның хатыны (ире) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәт характерындагы йөкләмәләре турында мәгълуматларны муниципаль хезмәткәрнең, аның хатыны (ире) һәм балигъ булмаган балаларының түли ала торган булуын ачыклау яки билгеләү өчен куллану рөхсәт ителми, иҗтимагый оешмалар, дини һәм башка оешмалар фондына, шулай ук физик затлар файдасына туры яки турыдан туры булмаган формада бүләк (кертем) җыю өчен куллану рөхсәт ителми.

3.6.4. Муниципаль хезмәткәрнең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәт характерындагы йөкләмәләре турында мәгълуматларны ачып салуда яки бу мәгълуматларны федераль закон белән каралмаган максатларда кулланган өчен гаепләнүче затлар Россия Федерациясе кануны белән туры китереп җаваплылыкка тартылалар.

3.6.5. Муниципаль хезмәткәрнең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәт характерындагы йөкләмәләре турында мәгълуматлар Россия Федерациясе норматив хокук актлары белән билгеләнгән тәртиптә массакүләм мәгълумат чараларында бастырып чыгару өчен бирелергә мөмкин.

Банк, салым һәм канун белән саклана торган башка серне тәшкил иткән мәгълуматларны бирү турында рәсми сорау, Югары Ослан муниципаль район Советы Карары белән расланган исемлеккә кергән муниципаль хезмәт вазифасын башкаручы муниципаль хезмәткәргә карата, муниципаль органнарның мәнфәгатьләрен чагылдырып, әлеге вазифаларны башкаручы муниципаль хезмәткәрләргә, мондый гражданнарның хатыны (ире) һәм балигъ булмаган балаларына һәм муниципаль хезмәткәрләргә карата оператив-

тентәү чараларын үткәрү турында хокук саклау органнарына рәсми сорау Россия Федерациясе норматив хокук актлары белән билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы югары хезмәт шәхесләре тарафыннан җибәрелә.

3.6.6. Югары Ослан муниципаль район Советы Карары белән расланган исемлеккә кергән муниципаль хезмәт вазифасын башкаруга дәгъва кылучы гражданинның керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәт характерындагы йөкләмәләре турында мәгълуматларның дөрес һәм тулы булуын тикшерү, Югары Ослан муниципаль район Советы Карары белән расланган исемлеккә кергән муниципаль хезмәт вазифасын башкаручы хезмәткәрнең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәт характерындагы йөкләмәләре турында мәгълуматларның дөрес һәм тулы булуын тикшерү, “Коррупциягә каршы тору турында” 2008нче елның 25нче декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законы билгеләгән вазифаларны башкару һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокук актлары белән муниципаль хезмәткәрнең чикләүләр һәм тыюларны, низах мәнфәгатьләрен китереп чыгармау яки җайга салу турында таләпләрне үтәү Татарстан Республикасы норматив хокук актлары билгеләгән тәртиптә тормышка ашырыла.

3.6.7. Муниципаль хезмәткә кергәндә гражданин яллаучы (эш бирүче) вәкилгә үзенең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәт характерындагы йөкләмәләре турында мәгълуматларны, шулай ук хатыны (ире) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәт характерындагы йөкләмәләре турында мәгълуматларны тапшырмау яки дөрес һәм тулы булмаган мәгълуматларны тапшыру әлеге гражданинны муниципаль хезмәткә алудан баш тартуга нигез булып тора.

3.6.8. Мондый мәгълуматларны тапшырмау һичшиксез кирәк булганда, муниципаль хезмәткәрнең үзенең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәт характерындагы йөкләмәләре турында мәгълуматларны, шулай ук хатыны (ире) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәт характерындагы йөкләмәләре турында мәгълуматларны тапшырмау яки дөрес һәм тулы булмаган мәгълуматларны тапшыру хокук бозу була, бу муниципаль хезмәткәрне муниципаль хезмәттән азат итүгә нигез булып тора.

3.6.9. Контракт буенча Башкарма комитет Җитәкчесе вазифасын башкаручыга дәгъва кылучы гражданнар, һәм бу вазифаны башкаручы шәхес үзләренең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәт характерындагы йөкләмәләре турында мәгълуматларны, шулай ук хатыны (ире) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәт характерындагы йөкләмәләре турында мәгълуматларны Татарстан Республикасы кануны белән билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Президентына тапшыралар.

3.6.10. Контракт буенча Башкарма комитет Җитәкчесе вазифасын башкаручы шәхеснең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәт характерындагы йөкләмәләре турында мәгълуматлар Югары Ослан муниципаль районы рәсми сайтында мәгълумати-телекоммуникацион “Интернет” челтәрендә һәм (яки) муниципаль хокук актлары билгеләгән тәртиптә массакүләм мәгълумат чараларында урнаштырыла.

3.6.11. Бу бүлекнең 3.6.9нчы пункты белән туры китереп шәхес тарафыннан тапшырылган керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәт характерындагы йөкләмәләре турында мәгълуматларының дөреслеген һәм тулы булуын тикшерү Татарстан Республикасы кануны белән билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Президенты карары буенча тормышка ашырыла.

3.6.12. Бу бүлекнең 3.6.11нче пункты белән туры китереп тормышка ашырылган тикшерү нәтиҗәсендә контракт буенча Башкарма комитет Җитәкчесе вазифасын башкаручы шәхес “Дәүләт вазифасын башкаручы затларның һәм башка затларның кереме белән чыгымнары туры килүен тикшерү турында” 2012нче елның 3нче декабрендәге 230- ФЗ номерлы Федераль законы , “Россия территориясеннән читтә булган чит ил банкларында акча саклау һәм счёт ачу аерым категория шәхесләргә тыелуы турында” 2013нче елның 7нче маендагы 79-ФЗ номерлы Федераль законы, “Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында” 2007нче елның 2нче мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законы белән билгеләнгән чикләүләр, тыюлар, вазифаларын башкармау ачыкланган очракта, Татарстан Республикасы Президенты контракт буенча Башкарма комитет Җитәкчесе вазифасын

башкаручы шәхеснең вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату турында гариза белән мөрәҗәгать итә, яки тиешле карар кабул итү вәкаләтләре булган җирле үзидарә органына, яки судка аңа карата башка дисциплинар җәза куллануны сорап мөрәҗәгать итә.

### 3.7. Районның муниципаль хезмәтендә низах мәнфәгатьләрен җайга салу.

3.7.1. Низах мәнфәгатьләре булып, низах мәнфәгатьләрен булдырмый калу яки җайга салу буенча чаралар күрү аның вазифасына кергән вазифа башкаручы шәхеснең шәхси кызыксынуы (туры яки туры булмаган) аңа үзенең хезмәт (эш) вазифаларын гадел һәм объектив башкарырга (вазифаларын тормышка ашырырга) тәэсир итә яки тәэсир итергә мөмкин булган хәлләр тора.

3.7.2. Шәхси кызыксыну булып, 3.7.1нче пунктта күрсәтелгән шәхес яки аның якын туган яки туганлык мөнәсәбәтләрендә булган кешеләр (әти-әнисе, ирле-хатынлы, балалары, абый-апалары, эне-сеңелләре, шулай ук ир-хатынның балалары, абый-апалары, эне-сеңелләре һәм балаларының ир-хатыннары) белән, мөлкәт, корпоратив һәм башка якын мөнәсәбәтләрдә булган гражданнар һәм оешмалар белән 3.7.1нче пунктында күрсәтелгән шәхес  якын туган булып акчалата, башка мөлкәт, шул исәптән мөлкәт хокукы, мөлкәт характерындагы ярдәм алу, башкарылган эш нәтиҗәләре яки ниндидер файда алу мөмкинлеге тора.

Низах мәнфәгатьләрен булдырмый калу яки җайга салу низах мәнфәгатьләре ягында булган муниципаль хезмәткәрнең вазифа яки хезмәт хәлен үзгәртүдән, хәтта билгеләнгән тәртиптә эшеннән алынудан яки низах мәнфәгатьләре килеп чыгуга сәбәп булган файдадан аның баш тартуыннан гыйбарәт була ала.

Муниципаль хезмәт вазифасын башкаручы шәхеснең кыйммәтле кәгазьләре (оешманың устав (склад) капиталында пайлар, катнашу өлеше)  булу  низах мәнфәгатьләрен китереп чыгырырга яки чыгарырга мөмкин булган очракта, әлеге шәхес аныкы булган кыйммәтле кәгазьләрне (оешманың устав (склад) капиталында пайлар, катнашу өлеше)  Россия Федерациясе гражданнар кануны белән туры китереп ышаныч оешмаларына тапшырырга тиеш.

Низах мәнфәгатьләре килеп чыгуга сәбәп булган муниципаль хезмәткәр тарафыннан низах мәнфәгатьләрен булдырмый калу яки җайга салу буенча чаралар күрмәү хокук бозу булып тора һәм бу аны муниципаль хезмәттән азат итүгә китерә.

3.7.3. Яллаучы (эш бирүче) вәкилгә Районның муниципаль хезмәткәренең низах мәнфәгатьләрен китереп чыгарган яки чыгарырга мөмкин булган шәхси кызыксынуы турында билгеле булгач,  низах мәнфәгатьләрен булдырмый калу яки җайга салу буенча чаралар күрергә тиеш, Районның муниципаль хезмәткәрен низах мәнфәгатьләрен җайга салганчы Районның муниципаль хезмәткәре вазифасыннан азат иткән вакытка акчалата түләүне саклап, аны башкарган вазифасыннан азат итергә тиеш.

Яллаучы вәкиле булган муниципаль хезмәткәр тарафыннан аңа буйсынучы шәхеснең низах мәнфәгатьләрен китереп чыгарган яки чыгарырга мөмкин булган шәхси кызыксынуы турында билгеле булгач,  низах мәнфәгатьләрен булдырмый калу яки җайга салу буенча чаралар күрмәсә, бу хокук бозу була, һәм бу яллаучы вәкиле булган муниципаль хезмәткәрне муниципаль хезмәттән азат итүгә китерә.

3.7.4. Муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан Районның муниципаль органында, башка муниципаль органнарда хезмәт тәртибенең гомуми принциплары һәм низах мәнфәгатьләрен җайга салуны тәэмин итү өчен  муниципаль хокук актлары белән билгеләнгән тәртиптә низах мәнфәгатьләрен җайга салу буенча комиссияләр оешырга мөмкин.

### 3.8. Муниципаль хезмәткәрнең хезмәт тәртибенә таләпләр.

1. Муниципаль хезмәткәр бурычлы:

1) хезмәт вазифаларын намуслы, югары профессиональ дәрәҗәдә башкарырга;

2) барлык юридик һәм физик затларга һәм оешмаларга тигез, беръяклы мөнәсәбәт тәэмин итергә, ниндидер иҗтимагый һәм дини оешмаларга, профессиональ һәм социаль төркемнәргә, гражданнарга һәм оешмаларга өстенлек бирмәскә, мондый оешмаларга, төркемнәргә, оешмаларга һәм гражданнарга карата алдан фактлар белән расланмаган очракларга юл куймаска;

3) хезмәт вазифаларын намуслы башкарырга комачаулаган ниндидер шәхси, мөлкәт (финанс) һәм башка мәнфәгатьләрнең тәэсире белән бәйле булган гамәлләр башкармаска;

4) үзенең профессиональ хезмәт вазифаларына сәясәт партияләре, башка иҗтимагый һәм дини оешмаларның һәм башка организацияләрнең карарлары тәэсир итү мөмкинлеген булдырмый калган битарафлыкны сакларга;

5) гражданнар белән мөгәләмәдә әдәплелек күрсәтергә;

6) Россия Федерациясе халыкларының әхлакый йолаларына һәм гореф-гадәтләренә хөрмәт күрсәтергә;

7) төрле этник һәм социаль төркемнәрнең культуралы һәм башка үзенчәлекләрен, шулай ук конфессияләрне исәпкә алырга;

8) милләтара һәм конфессия ара килешүләргә булышлык итергә;

9) муниципаль органның дәрәҗәсенә һәм абруена зыян китерә ала торган низах хәлләрен булдырмый калырга.

2. Җитәкче булып торган муниципаль хезмәткәр муниципаль хезмәткәрләрнең сәяси партияләр, башка иҗтимагый һәм дини оешмаларның эшчәнлегендә катнашырга мәҗбүр иткән очракларын булдырмый калырга тиеш.

## 4. Районның муниципаль хезмәтенә керү, аны узу һәм туктату тәртибе.

### 4.1. Районның муниципаль хезмәтенә керү.

4.1.1. Районның муниципаль хезмәтенә 18 яше тулган, Россия Федерациясе дәүләт телен белгән һәм Федераль кануннар, Татарстан Республикасы кануннары һәм бу Кагыйдәнамәнең квалификация таләпләренә туры килгән, муниципаль хезмәт белән бәйле чикләүләр булмаган гражданнар керә ала.

4.1.2. Районның муниципаль хезмәтенә кергән вакытта, шулай ук аны үтәгән вакытта җенесенә, расасына, милләтенә, килеп чыгышына, мөлкәт һәм хезмәт хәленә, яшәү урыннына, дингә мөнәсәбәтенә, карашларына, җәмәгать оешмаларына керүенә, шулай ук муниципаль хезмәткәрнең профессиональ һәм эшлекле сыйфатлары белән бәйле булмаган башка хәлләргә карамастан, нинди дә булса туры яки туры булмаган чикләүләр яки өстенлекләр билгеләнергә тиеш түгел.

4.1.3. Районның муниципаль хезмәтенә кергән вакытта гражданин тапшыра:

1) Районның муниципаль хезмәтенә керү һәм Районның муниципаль хезмәт вазифасын башкару турында гаризасы;

2) Россия Федерациясе Хөкүмәтенең башкарма власте федераль органы вәкиле тарафыннан билгеләнгән форма буенча үз кулы белән тутырылган һәм имзаланган анкета;

3) паспорт;

4) хезмәт кенәгәсен һәм (яки) хезмәт эшчәнлеге турында законнарда билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән белешмәләр, хезмәт килешүе (контракт) беренче тапкыр төзелгән очраклардан тыш;

5) белем турында документы;

6) мәгәр хезмәт килешүе (контракт) беренче тапкыр төзелгән булмаса, пенсияне мәҗбүри иминиятләштерү имминият таныклыгы;

7) Россия Федерациясе территориясендә яшәү урыны буенча салым органнарында физик затны исәпкә алу турында таныклык;

8) запастагы гражданнар өчен һәм хәрби хезмәткә чакырылырга тиешле шәхесләрнең хәрби исәпкә алу документлары;

9) Районның муниципаль хезмәтенә керү өчен комачаулаган авыруы булмау турында медицина оешмасы нәтиҗәсе;

10) Районның муниципаль хезмәтенә кергәнче алдагы бер елга керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәт характерындагы йөкләмәләре турында мәгълумат;

10.1) “Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында” Федераль канунның 15.1нче статьясында исәпкә алынган мәгълуматлар;

11) федераль кануннар, Россия Федерациясе Президенты указлары һәм Россия Федерациясе Хөкүмәте карарлары белән исәпкә алынган башка документлар.

4.1.4. Районның муниципаль хезмәтенә керү «Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы белән» Татарстан Республикасы законы билгеләгән тәртиптә тормышка ашырыла.

4.2. Муниципаль вазифаны алыштыруга конкурс.

4.2.1. Районда муниципаль вазифаны алыштыру вакытында хезмәт килешүен төзегәндә аның алдыннан Районның муниципаль хезмәте вазифасына дәгъва кылучыларның профессиональ дәрәҗәсен тикшерү, Районның муниципаль хезмәте вазифасына билгеләнгән квалификация таләпләренең туры килүе тормышка ашырылган конкурс була.

4.2.2. Муниципаль вазифаны алыштыруга конкурс үткәрү тәртибе Район Советы кабул иткән муниципаль хокук акты белән билгеләнә. Конкурсны үткәрү тәртибе бастырылып чыгарылган аның шартларын, датасы турында мәгълуматны, вакытын һәм аны үткәрү урынын конкурс үткәрер алдыннан 20 көннән дә соңга калмыйча алдан ук күздә тотырга тиеш.

4.2.3. Яллаучы (эш бирүче) вәкил хезмәт килешүен төзи һәм Районның муниципаль хезмәте вазифасына муниципаль вазифаны алмаштыруга конкурс нәтиҗәләре буенча конкурс комиссиясе сайлап алган кандидатларның берсен билгели.

4.3. Районның муниципаль хезмәткәрләренә аттестация.

4.3.1. Муниципаль хезмәткәргә аттестация аның муниципаль хезмәт вазифасын башкаручыга туры килүен билгеләү максатыннан үткәрелә. Муниципаль хезмәткәргә аттестация өч елга бер тапкыр үткәрелә.

4.3.2. Түбәндәге муниципаль хезмәткәрләр аттестация узарга тиеш түгел:

1) муниципаль хезмәт вазифасын бер елдан ким башкарса;

2) 60 яше тулса;

3) йөкле хатыннар;

4) йөклелек буенча һәм бала тапкач ялда булса яки балага өч яшь тулганчы баланы карау буенча ялда булса. Күрсәтелгән муниципаль хезмәткәрләргә аттестация алар ялдан чыкканнан соң бер елдан булырга мөмкин.

5) муниципаль хезмәт вазифаларын сроклы хезмәт килешүе (контракт) нигезендә башкаручы.

4.3.3. Муниципаль хезмәткәргә аттестация үткәрү тәртибе Татарстан Республикасы муниципаль хезмәт турында Кодексы белән билгеләнә.

4.4. Районның муниципаль хезмәткәре белән хезмәт килешүен өзүгә нигез.

4.4.1. Муниципаль хезмәткәр белән хезмәт килешүен өзү яллаучы (эш бирүче) вәкил инициативасы буенча түбәндәге очракларда була:

1) Районның муниципаль хезмәте вазифасын башкару өчен билгеләнгән яше җиткү;

2) Россия Федерациясе гражданлыгы бетсә, Россия Федерациясе халыкара килешү катнашучысы-чит дәүләт гражданлыгы бетә, чит дәүләт гражданлыгын яки торырга рөхсәт алса, шуңа күрә чит ил гражданины муниципаль хезмәттә була ала;

3) муниципаль хезмәт вазифасын башкару белән бәйле чикләүләр һәм тыюларны сакламаса;

4) квалификациясеннән мәхрүм итү белән бәйле административ җәза кулланылса.

4.4.2. Муниципаль хезмәткәрнең муниципаль хезмәттә булу вакытын озынайту муниципаль хезмәт вазифасын башкару өчен билгеләнгән яше җиткән очракта мөмкин.

Муниципаль хезмәткәрнең муниципаль хезмәттә булу вакытын бер тапкыр озынайту бер елга гына рөхсәт ителә.

## 5. Эш (хезмәт) вакыты һәм ял вакыты.

### 5.1. Эш (хезмәт) вакыты.

5.1.1. Муниципаль хезмәткәрләрнең эш (хезмәт) вакыты хезмәт турында канун белән туры китереп тәртипкә салына.

### 5.2. Муниципаль хезмәткәрләрнең ял вакыты.

5.2.1. Муниципаль хезмәткәргә муниципаль хезмәттәге вазифасын һәм уртача хезмәт хакын билгеләү өчен хезмәт турында канун белән гамәлгә кертелгән тәртиптә күләме билгеләнгән хезмәт хакын саклап, еллык ял бирелә.

5.2.2. Муниципаль хезмәткәрнең еллык түләүле ялы төп түләүле ялдан һәм өстәмә түләүле ялдан тора.

5.2.3. Муниципаль хезмәткәрләргә 30 календарь көн дәвамлылык белән төп түләүле ял бирелә.

5.2.4. Муниципаль хезмәткәргә еллык өстәмә түләүле яллар тиешле еллар хезмәт иткән өчен, шулай ук федераль кануннар һәм Татарстан Республикасы кануннары белән каралган очракларда бирелә. Муниципаль хезмәткәргә тиешле еллар хезмәт иткән өчен еллык өстәмә түләүле яллар дәвамлылыгы муниципаль хезмәттә булган һәр елы өчен бер календарь көн исәбеннән санала. Муниципаль хезмәткәрнең еллык төп түләүле ялы һәм тиешле еллар хезмәт иткән өчен өстәмә түләүле ялы 40 календарь көннән артып китергә тиеш түгел.

Нормадан тыш хезмәт көне билгеләнгән муниципаль хезмәткәр өчен нормадан тыш хезмәт көне өчен өч календарь көне дәвамлылыгы белән өстәмә түләүле ял бирелә.

Нормадан тыш хезмәт көне өчен өстәмә түләүле ял, шулай ук федераль канун белән каралган башка очракларда бирелгән еллык өстәмә түләүле яллар әлеге пункт белән каралган еллык төп түләүле ял һәм тиешле еллар хезмәт иткән өчен өстәмә түләүле яллардан күбрәк була.

5.2.5. Муниципаль хезмәткәрнең гаризасы буенча еллык түләүле ял өлешләп бирелергә мөмкин, шул ук вакытта ялның бер өлеше 14 календарь көненнән ким булырга тиеш түгел. Яллаучы (эш бирүче) вәкил белән килешү нәтиҗәсендә муниципаль хезмәткәргә өлешле ялның дәвамлылыгы башкача бирелергә мөмкин.

5.2.6. Муниципаль хезмәткәргә аның язмача гаризасы буенча яллаучы (эш бирүче) вәкил карары белән хезмәт хакын сакламыйча бер елдан артмаган ял бирелә.

5.2.7. Муниципаль хезмәткәргә хезмәт хакын сакламыйча ял федераль канун белән каралган очракларда бирелә.

## 6. Муниципаль хезмәткәрнең хезмәтенә түләү, муниципаль хезмәткәргә бирелгән гарантияләр. Муниципаль хезмәт стажы.

### 6.1. Муниципаль хезмәткәрнең хезмәтенә түләү.

6.1.1. Муниципаль хезмәткәрнең акчалата хезмәт хакы муниципаль хезмәттә аның башкарган вазифасына туры китереп муниципаль хезмәткәрнең хезмәт окладыннан (алда-хезмәт оклады), шулай ук айлык һәм башка өстәмә түләүләрдән (алда-өстәмә түләүләр) тора.

6.1.2. Өстәмә түләүләргә керә:

1) тиешле еллар хезмәт иткән өчен хезмәт окладына айлык өстәмә;

2) муниципаль хезмәттә аерым шартлар өчен хезмәт окладына айлык өстәмә;

3) яллаучы (эш бирүче) вәкил тарафыннан муниципаль оешманың функцияләрен һәм бурычларын тәэмин итүне исәпкә алып, хезмәт инструкциясен үтәп түләү тәртибе билгеләнгән аерым мөһим һәм авыр мәсьәләләрне үтәгән өчен премия;
4) еллык акчалата бүләкләү;
5) класслы чин өчен айлык өстәмә түләү;
6) еллык түләүле ял бирелгән вакытта бер тапкыр түләү;
7) матди ярдәм.

6.1.3. Районның муниципаль хокук актлары белән шулай ук түбәндәге өстәмә түләүләрне билгеләү каралырга мөмкин:

1) нормадан тыш хезмәт көне шартларында эшләгән өчен муниципаль хезмәткәргә айлык компенсация түләү;
2) төп хезмәт вазифалары булган хокук актларына һәм хокук актлары проектларына хокук экспертизасы үткәрү, хокук актлары проектларын әзерләү һәм редакцияләү һәм юрист яки башкаручы сыйфатында аларны визалаган өчен югары юридик белеме булган муниципаль хезмәткәргә айлык түләү (юридик эш өчен түләү);
3) профилле фән кандидаты гыйльми дәрәҗәсе өчен, фән докторы гыйльми дәрәҗәсе өчен муниципаль хезмәткәргә хезмәт окладына айлык өстәмә түләү;
4) Татарстан Республикасының мактаулы исеме өчен муниципаль хезмәткәргә хезмәт окладына айлык өстәмә түләү.

6.1.4. Муниципаль хезмәткәргә канун белән туры китереп, дәүләт серен тәшкил иткән мәгълуматлар белән эшләгән өчен хезмәттәге окладына айлык өстәмә түләү билгеләнә.

6.1.5. Муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәтенә түләү күләмен һәм шартларын Районның җирле үзидарә органнары мөстәкыйль рәвештә билгелиләр. Хезмәт окладының күләме, шулай ук айлык һәм башка өстәмә түләүләр күләме һәм аларны тормышка ашыру Россия Федерациясе кануны, Татарстан Республикасы канунына туры китереп Район Советы тарафыннан чыгарылган муниципаль хокук актлары белән билгеләнә.

6.2. Муниципаль хезмәткәргә бирелгән гарантияләр.

6.2.1. Муниципаль хезмәткәргә гарантияләр бирелә:

1) хезмәт инструкциясе белән туры китереп аның хезмәт вазифаларын башкаруын тәэмин итә торган эш шартлары;
2) вакытында һәм тулы күләмдә хезмәт хакын алуга хокук;
3) эш (хезмәт) вакытының нормаль дәвамлылыгын билгеләү белән тәэмин ителгән ял, ял көннәре һәм бәйрәм көннәре, шулай ук еллык түләүле төп һәм өстәмә ялга хокук;
4) муниципаль вазифа башкарган кешегә һәм аның гаиләсенә, шул исәптән муниципаль вазифа башкарган кеше пенсиягә чыкканнан соң медицина ярдәме күрсәтү;
5) муниципаль вазифа башкарган кеше тиешле еллар хезмәт иткән өчен һәм инвалидлык очрагында пенсия белән тәэмин ителергә, шулай ук муниципаль вазифа башкарган кеше, үзенең вазифасын башкарган вакытта үлгән очракта, аның гаиләсен пенсия белән тәэмин итү ;
6) муниципаль вазифа башкарган кешегә, үзенең вазифасын башкарган вакытта сәламәтлегенә һәм мөлкәтенә зыян килгән очракта дәүләт социаль иммынияте;
7) муниципаль вазифа башкарган кешегә, үзенең вазифасын башкарган вакытта яки ул туктатылганнан соң муниципаль хезмәт башкарганда авырган һәм хезмәткә яраклылыгын югалткан очракта, мәҗбүри дәүләт социаль иммынияте;
8) федераль кануннар белән билгеләгән тәртиптә, шартларда һәм очракта үзенең вазифасын башкарган вакытта көчләү, янаулар һәм башка аның хокукларын бозган гамәлләрдән муниципаль вазифа башкарган кешене һәм аның гаиләсен яклау.

6.2.2. Җирле үзидарә органы, Районның башка муниципаль органнары бетерелү белән, яки Районның җирле үзидарә органы, Районның башка муниципаль органнары эшчеләр штаты кыскартылуга бәйле очракта хезмәт килешүе өзелгән вакытта муниципаль хезмәткәргә муниципаль органнары бетерелү яки эшчеләр штаты кыскартылу белән бәйле булган аларны эштән чыгару очрагында эшчеләр өчен хезмәт турында канун белән билгеләнгән гарантияләр каралган.

6.2.3. Татарстан Республикасы кануны һәм Район уставы белән муниципаль хезмәткәргә өстәмә гарантияләр каралган.

6.3. Муниципаль хезмәткәрне һәм аның гаилә әгъзаларын пенсия белән тәэмин итү.

6.3.1. Районның җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәт вазифаларын башкарган Районның муниципаль хезмәткәрләренең Татарстан Республикасы кануны белән билгеләнгән шартлар булган очракта тиешле еллар хезмәт иткән өчен пенсия алырга хакы бар.

6.3.2. Көчен югалтты.

6.3.3. Муниципаль хезмәткәргә тиешле еллар хезмәт иткән өчен пенсия күләмен билгеләү Татарстан Республикасы кануны белән билгеләнгән муниципаль хезмәт вазифасының һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең бәйләнешенә туры китереп тормышка ашырыла. Муниципаль хезмәткәрнең тиешле еллар хезмәт иткән өчен максималь пенсия күләме Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең тиешле вазифасы буенча Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәренең тиешле еллар хезмәт иткән өчен максималь пенсия күләменнән артып китергә тиеш түгел.

6.3.4. Муниципаль хезмәткәрнең хезмәт пенсиясенә тиешле еллар хезмәт иткән өчен айлык өстәмә түләүнең минималь күләме Россия Федерациясе кануны белән билгеләнгән картлык буенча хезмәт пенсиясенең минималь күләменнән ким булырга тиеш түгел.

6.3.5. Федераль канун белән билгеләнгән тәртиптә, муниципаль вазифа башкарган кеше, үзенең вазифасын башкарган вакытта үлгән очракта, шул исәптән муниципаль хезмәттән алынгач үлгән очракта, аның гаиләсе карауучысын югалту очрагы буенча пенсия алырга хокуклы;

6.3.6. Муниципаль хезмәткәргә Югары Ослан муниципаль районы Советы карары билгеләгән тәртиптә пенсиягә чыгу сәбәпле бер тапкыр акчалата түләү каралган.

6.4. Район муниципаль хезмәтенең стажы.

6.4.1. Тиешле еллар хезмәт иткән өчен пенсия билгеләгәндә Районның муниципаль хезмәт стажына (гомуми дәвамлылыгы ) даими (штат) нигездә эшләгән (алыштырган) вакыты кертелә:

1) Районның муниципаль хезмәт вазифасында (Районның муниципаль хезмәтенең муниципаль вазифасында);

2) муниципаль вазифаларда;

3) Россия Федерациясе дәүләт вазифаларында һәм Татарстан Республикасы дәүләт вазифаларында;

4) дәүләт граждан хезмәте вазифалары, хәрби вазифалар һәм хокук саклау хезмәте вазифаларында (дәүләт хезмәтенең дәүләт вазифаларында);

5) Татарстан Республикасының хезмәт турында Кодексы белән туры китереп башка вазифалар.

6.4.2. Татарстан Республикасы дәүләт вазифаларын һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазифаларын, Татарстан Республикасының (Татарстан АССР) дәүләт органнарында башка дәүләт вазифаларын башкарган вакыты Татарстан Республикасы кануны белән туры китереп муниципаль хезмәт стажына кертелә.

6.4.3. Тиешле еллар хезмәт иткән өчен пенсия билгеләгәндә Татарстан Республикасы кануны белән туры китереп Районның муниципаль хезмәткәре тарафыннан тормышка ашырылган өстәмә профессиональ белем алган вакыты кертелә, шулай ук федераль кануннар белән туры китереп Районның муниципаль хезмәткәре муниципаль хезмәт башкарган башка вакытлары керә.

6.4.4. Муниципаль хезмәткәрләргә бирелә торган тиешле еллар хезмәт иткән өчен түләүле өстәмә еллык отпускны билгеләү өчен, һәм гамәлдәге канун белән исәпкә алынган башка гарантияләрне аңа билгеләү өчен муниципаль хезмәт стажына “Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында” Федераль кануның 25нче маддәсенең 1нче өлешендә күрсәтелгән вазифаларны башкару вакыты кертелә (исәпләнә), шулай ук “Россия Федерациясендә дәүләт граждан хезмәте турында” 2004нче елның 27нче июленнән 79-ФЗ Федераль канунының 54нче статьясының 2нче өлеше белән туры китереп дәүләт

граждан хезмәте стажына кертелгән (саналган) вазифаларны башкару вакыты кертелә (санала).

6.4.5. Муниципаль хезмәт стажын санау һәм билгеләү тәртибе Татарстан Республикасы кануны белән билгеләнә.

## 7. Районның муниципаль хезмәткәрен бүләкләү. Районның муниципаль хезмәткәренең дисциплинар җаваплылыгы.

### 7.1. Районның муниципаль хезмәткәрен бүләкләү.

7.1.1. Районның муниципаль хезмәткәренә үзенең хезмәт вазифаларын намуслы һәм нәтиҗәле башкарганы өчен, бик яхшы хезмәте өчен, мөһим әһәмиятле һәм авыр йөкләмәләрне үтәгән өчен аңа карата түбәндәге бүләкләүләр каралган:

1) рәхмәт белдерү;

2) бер тапкыр акчалата түләү;

3) кыйммәтле бүләк белән бүләкләү;

4) Районның җирле үзидарә органнары билгеләгән мактау грамоталары һәм башка төрдәге бүләкләүләр;

5) Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы кануннары белән туры китереп дәүләт бүләкләре белән бүләкләү;

6) Район Уставы белән һәм башка федераль кануннар һәм Татарстан Республикасы кануннары белән туры китергән башка төрдәге бүләкләүләр.

7.1.2. Бүләкләүләрне куллану тәртибе һәм шартлары Районның муниципаль хокук актлары белән билгеләнә.

### 7.2. Районның муниципаль хезмәткәренең дисциплинар җаваплылыгы.

7.2.1. Дисциплинар ярамаган гамәл башкарганы өчен – Районның муниципаль хезмәткәре тарафыннан аңа йөкләнгән хезмәт вазифаларын аның гаебе аркасында үтәмәүе яки тиешенчә үтәмәүе өчен - яллаучы (эш бирүче) вәкил түбәндәге дисциплинар җәза кулланырга хокуклы:

1) кисәтү;

2) шелтә;

3) тиешле сәбәпләр буенча районның муниципаль хезмәтеннән чыгару.

7.2.2. Дисциплинар ярамаган гамәл башкарган муниципаль хезмәткәр, аның дисциплинар җаваплылыгы турында мәсьәлә чишелгәнгә кадәр (ләкин бер айдан да артмаган вакытка), акчалата түләүне саклап вакытлыча хезмәт вазифаларын башкарудан азат ителергә мөмкин. Муниципаль хезмәткәрне хезмәт вазифаларын башкарудан азат итү бу очракта Районның муниципаль хокук акты белән башкарыла.

7.2.3. Дисциплинар җаваплылык куллану һәм өстеннән төшерү тәртибе хезмәт турында канун белән билгеләнә.

### 7.3. Мәнфәгатьләр каршылыгын булдырмау яки җайга салу турындагы таләпләрне, чикләүләрне һәм тыюларны үтәмәгән һәм коррупциягә каршы тору максатларында билгеләнгән бурычларны үтәмәгән өчен түләтүләр.

7.3.1. Мәнфәгатьләр каршылыгын булдырмау яки җайга салу турындагы таләпләрне, чикләүләрне һәм тыюларны үтәмәгән һәм коррупциягә каршы тору максатларында билгеләнгән бурычларны үтәмәгән өчен “Коррупциягә каршы тору турында” 2008нче елның 25нче декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законы билгеләгән әлеге кагыйдәнамәнең 7.2нче статьясы белән каралган шелтә бирелә.

7.3.2. Бу Кагыйдәнамәнең 3.6нчы һәм 3.7нче статьялары билгеләгән хокук бозулар булган очракта ышынычын югалтса муниципаль хезмәткәр муниципаль хезмәттән алына.

7.3.3. Бу Кагыйдәнамәнең 3.6нчы һәм 3.7нче һәм 7.2нче статьяларында каралган шелтәләр яллаучы (эш бирүче) вәкил тарафыннан Татарстан Республикасы норматив хокук актлары һәм муниципаль норматив хокук актлары билгеләгән тәтиптә түбәндәге нигезләрдә кулланыла:

1) коррупцион һәм башка хокук бозуларны профилактика үткәрү буенча тиешле муниципаль органның оештыру бүлеге үткәргән тикшерү нәтиҗәләре турында доклад;
2) үткәргән тикшерү нәтиҗәләре турында доклад комиссиягә җибәрелгән очракта, муниципаль хезмәткәрнең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәү буенча һәм низах мәнфәгатьләрен җайга салу буенча комиссиянең тәкъдимнәре;
3) муниципаль хезмәткәрнең аңлатмалары;
4) башка материаллар.
7.3.4. Бу Кагыйдәнамәнең 3.6нчы һәм 3.7нче һәм 7.2нче статьяларында каралган шелтәләр кулланганда муниципаль хезмәткәр башкарган коррупцион хокук бозуның характеры, аның авырлыгы, ул башкарылган шартлар, муниципаль хезмәткәр тарафыннан башка чикләүләрне һәм тыюларны үтәүе, низах мәнфәгатьләрен булдырмый калу яки җайга салу турында таләпләрне үтәү һәм аның тарафыннан коррупциягә каршы тору максатында билгеләнгән вазифаларны башкару, шулай ук муниципаль хезмәткәрнең үз вазифаларын башкаруының моннан алдагы нәтиҗәләре күздә тотыла.
7.3.5. Муниципаль хезмәткәргә карата шелтә аның тарафыннан коррупцион хокук бозу башкарган очракта шелтә куллану турындагы нигез булып әлеге статьяның 1нче һәм 2нче өлешләре актта күрсәтелә.
7.3.6. Бу Кагыйдәнамәнең 3.6нчы һәм 3.7нче һәм 7.2нче статьяларында каралган шелтәләр федераль законнар, Татарстан Республикасы законы һәм (яки) Югары Ослан муниципаль районының муниципаль норматив хокук актлары белән билгеләнгән тәртиптә һәм вакытта кулланыла.

8.1. Районның җирле үзидарә органнарында кадрлар хезмәте.

8.1.1. Районның җирле үзидарә органнарында кадрлар хезмәте үз эченә түбәндәгеләрне ала:
1) районның муниципаль хезмәте вазифаларын башкару өчен кадрлар составын формалаштыру;
2) районның муниципаль хезмәте турында закон кагыйдәнамәләрен тормышка ашыру турында тәкъдимнәрне әзерләү һәм әлеге тәкъдимнәрне яллаучы (эш бирүче) вәкилгә тапшыру;
3) муниципаль хезмәткә керү, аны узу, хезмәт килешүләре (контракт) төзү, муниципаль хезмәт вазифасына билгеләү, муниципаль хезмәткәрне муниципаль хезмәттән азат итү һәм аның пенсиягә чыгуы, һәм тиешле документларны рәсмиләштерү белән бәйле булган муниципаль хокук актлары проектларын әзерләү;
4) муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт кенәгәләрен алып бару (булганда), муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан муниципаль хезмәт узган чорда хезмәт эшчәнлеге турында мәгълүматлар формалаштыру һәм әлеге белешмәләрне мәҗбүри пенсия иминияте системасында индивидуаль (персональләштерелгән) исәпкә алу турында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә, Россия Федерациясе Пенсия фондының мәгълүмат ресурсларында саклау өчен бирү;
5) “Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында” Федераль законы белән билгеләнгән тәртиптә муниципаль хезмәткәрләрнең шәхси делосын алып бару;
6) районда муниципаль хезмәткәрләрнең исемлеген алып бару;
7) муниципаль хезмәткәрләргә хезмәт таныклыкларын рәсмиләштерү һәм бирү;
8) муниципаль хезмәтнең буш вазифаларына конкурс үткәрү һәм муниципаль хезмәткәрләрне кадрлар резервына кертү;
9) муниципаль хезмәткәрләргә аттестация уздыру;
10) кадрлар резервы белән эшне оештыру һәм аны нәтиҗәле куллану;
11) муниципаль хезмәткә кергән вакытта гражданин тарафыннан тапшырылган аерым мәгълуматларның һәм башка мәгълуматларының дөреслеген тикшерүне оештыру, шулай ук дәүләт сере булган мәгълуматларга керүнең тиешле формасын рәсмиләштерү;
12) муниципаль хезмәткәрләрнең керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәт характерындагы бурычлары турында мәгълуматларны тикшерүне оештыру, шулай ук “Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында” Федераль законы һәм башка федераль законнар белән билгеләнгән муниципаль хезмәткә чикләүләрне үтәүне оештыру;

13) муниципаль хезмәткәрләргә муниципаль хезмәтнең хокук һәм башка мәсъәләләре буенча киңәш бирү;

14) хезмәт турында закон һәм Татарстан Республикасының муниципаль хезмәт турында Кодексы тарафыннан билгеләнгән кадрлар хезмәте буенча башка мәсьәләләрне чишү.

8.2. Муниципаль хезмәт өчен кадрларны килешү нигезендә әзерләү.

8.2.1. Муниципаль хезмәт өчен гражданнарны килешү нигезендә әзерләү Россия Федерациясенең "Берәмлекләр турында" Закон Кагыйдәнамәсен һәм "Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында" Федераль законны исәпкә алып Татарстан Республикасының муниципаль хезмәт турында Кодексына туры китереп тормышка ашырыла.

Совет рәисе,
Югары Ослан муниципаль районы
Башлыгы М.Г. Зиатдинов